# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлегенең Кәүҗияк торак пунктында 2026 елда гражданнарның үзара салым кертү турында

**2025 елның 24 ноябре** **№2**

2025 елның 20 мартындагы «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 маддәсе, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлегенең Кәүҗияк торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк Кәүҗияк авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, I төркем инвалидларыннан, ялгыз өлкән яшьтәге гражданнардан (80 яшькә җиткәннәр), көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, һәм вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар, Украина территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучылардан кала, 2026 елда 600 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1) Кәүҗияк торак пункты территориясен төзекләндерү (Кәүҗияк торак пунктындагы территориядә үлән чаптыру (эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү); газ саз 3512 махсуслаштырылган техникасын(үзбушаткыч йөк машинасы) һәм МТЗ-82 тракторын тоту: дизель ягулыгы, дизмай, запас частьлар сатып алу);

2) Ремонт, киртәләр кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (зиратны ремонтлау (Совет урамындагы Кәүҗияк торак пунктындагы зиаратка төзелеш материаллары сатып алу); зират өчен бензопила сатып алу);

3) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Тукай - Совет урамнары арасындагы Кәүҗияк торак пунктында вак таш түшәмәләрен ремонтлау (вак таш ташу));

4) су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, алар су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә (Кәүҗияк авылындагы су җыю манарасын алмаштыру, Тукай ур., 112а йорт).

3. Җыен нәтиҗәләрен Кәүҗияк авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http://sarmanovo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән 7 көн эчендә бастырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Сарман муниципаль районы
Кәүҗияк авыл җирлеге башлыгы ____________ Ф. Ә. Хөснетдинов